Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Урман Кәләй авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАРЫ

18 май 2022ел №8

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлеге башкарма комитетының 2012 елның 30 мартында кабул ителгән 3А номерлы«Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәте вазыйфасын биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Әлмәт муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен масса күләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен раслау турында »карарына үзгәрешләр кертү турында

«Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында»2020 елның10 декабрендәге 778 номерлы РФ Президенты Указы нигезендә,Әлмәт шәһәре прокуратурасының 19.04.2022 елның 02-08-02/149-2022 номерлы протестын карап

Урман Кәләй авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлеге башкарма комитетының 2012 елның 30 мартында кабул ителгән 3А номерлы "Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәте вазыйфасын биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Әлмәт муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтаның 2 пунктындагы г) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасын, кыймммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хезмәткәрнең (хезмәткәрнең) һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып киткән очракта, акча алу чыганаклары турында белешмәләр.»;

карарга 2 нче кушымта формасында «акциялəр» сүзен төшереп калдырырга;

карар исемендə һəм алга таба да карарның һəм 1 нче кушымтаның барлык тексты буенча тиешле килештə «рəсми сайт» сүзлəрен «Интернет «мəгълүмат-телекоммуникация челтəренең Əлмəт муниципаль районы сайтында» сүзлəре белəн алмаштырырга.

2 Əлеге карарны торак пункт территориясендə урнашкан махсус мəгълүмат стендында игълан итəргə: Кəлəй тимер юл станциясе бистəсе, Железнодорожная урамы, 38б йорты; Колшəрип тимер юл станциясе бистəсе, «Татарстан Республикасы хокукый мəгълүматының рəсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU),«Интернет»мəгълүмат-телекоммуникация челтəренең Əлмəт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Əлеге карар рəсми басылып чыкканнан соң үз көченə керə.

4. Əлеге карарның үтəлешен контрольдə тотуны үземдə калдырам.

Урман Кəлəй авыл җирлеге
башкарма комитеты җитəкчесе — Л.Н.Фəлəхиев